ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына һәм “Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында” 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында “дәүләт статистика органы” сүзләрен “федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматын булдыру функциясен гамәлгә ашыручы органы” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда “федераль башкарма хакимиятнең статистика органына” сүзләрен “федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматын булдыру функциясен гамәлгә ашыручы органына” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында минимальь куллану бюджеты турында” 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы алтынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (I өлеш); 2013, № 7), “дәүләт статистика органының” сүзләрен “федераль башкарма хакимиятнең Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматын булдыру функциясен гамәлгә ашыручы органының” сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 26 октябрь
№ 78-ТРЗ